## Сәхнәдә яшь артистлар...

Безнең мәктәпнең 1-4 нче сыйныфы укучылары курчак театрын сәхндә күрсәттеләр. Алар А.Алишның «Сертотмас үрдәк» әкиятен һәм «Батыр әтәч» исемле татар халык әкиятен сәхнәләштерделәр. «Батыр әтәч» әкияте белән «Без бергә» бәйгесенең муниципаль этабында катнашып, 1 нче дәрәҗәдәге лауреат исеменщәлаек булдылар.





Татарстан Республикасы Минзәлә шәһәренең

"Знче урта гомуми белем мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе

Мәктәп телефоны: 8855553-44-20

Татарстан Республикасы Минзәлә шәһәренең

"Знче урта гомуми белем мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе

# Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы






**2021 нче ел**

## Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын ачу тантанасы.

2021 нче ел туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Бүгенге көн шартларында бу бик мөһим.

Татарстаныбызда дүрт миллионга якын кеше яши. Күпчелеген татарлар һәм руслар тәшкил итә. Шулай ук чуашлар,



марилар, удмуртлар, мордвалар h.б. милләт вәкилләре дә бар. Безнең мәктәптә дә төрле милләт балалары



укый: руслар, татарлар, марилар, таҗиклар, украиннар, әрмәннәр. Алар үзләренең телләрен камил беләләр, шуңа да бу бәйрәмдә үз телләрендә исәнләшеп, телләр турында кызыклы сүзләр әйттеләр. Күп кенә милләт укучылары татар телен дә теләп өйрәнәләр. Алар татар телендә шигырьләр, җырлар беләләр, биюләр башкаралар, уеннар уйныйлар.



### Рәсәй халыкларының фестивале

Районыбызда инде икенче ел рәттән Рәсәй халыкларының фестивале үткәрелә. Анда төрле мәктәп укучылары һәм укытучылары чыгыш ясый ала. Фестивальдә бер милләт вәкилләренең гйолалары, бәйрәмнәре турында сәхнәләштерү әзерләргә кирәк. Быелгы чарада башлангыч сыйныфлары актив катнашты. Алар номинациядә җиңүчеләр булдылар.

«Халыклар дуслыгы» темасына күргәзмә.

Мәктәптә күргәзмә эшләде. Ул укучылар, әтиәниләр һәм укытучылар ярдәме белән оештырылды. Күргәзмәдәге һәр экспонат игътибарга лаек,чөнки аны күп тырышлык белән ясаганнар. Шулай ук бу ясалган әйберләр шәһәребезнең ярминкәләрендә дә күрсәтелде һәм сатылды.



«Карга боткасы» уены.

Башлангыч сыйныфы укучылары өчен карга боткасы үткәрелде. Укучылар каргаларга ботка бирделәр, төрле уеннарда катнаштылар..Бәйрәм бик күңелле үтте.



Дәрестән соң укучыларыбыз да кул эшләре ясау белән шөгыльләнәләр. Алар бу истәлекле елны каршылап, төрле өй кирәк– яраклары әзерлиләр, уенчыклар ясыйлар һәм аларны милләт орнаментлары белән бизиләр.



**«Сәләт» түгәрәге .**

«Сәләт» түгәрәгенә 5-9 нчы сыйныфы укучылары йөри. Анда төрле милләт балалары катнаша. Яшь артистлар сәхнәдә пьесаларны күрсәтәләр, театр осталыгына өйрәнәләр.





